ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы мәдәният министры вазыйфаларын башкаручы Ю.И. Әдһәмованың Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2025 елның 26 декабрендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Рәисе Указы белән төзелгән Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты эшен координацияләүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Татарстан Республикасы Милли музее белән берлектә Габдулла Тукайның иҗади мирасын популярлаштыру эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән берлектә ел дәвамында Габдулла Тукай тормышына һәм иҗатына багышланган музейларга, күргәзмә һәм агарту проектларына мәгариф оешмалары педагогларының һәм укучыларының баруларын оештыруны тәкъдим итәргә.
5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында уздырыла торган чараларда катнашуны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 17 марты
№ 601-VII ДС